КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 сентябрь

г.Казань

№ 1088

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәктән билгеләүне оештыру мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2008 ел, 28 август, 615 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәктән билгеләүне оештыру мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2008 ел, 28 август, 615 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 26 сентябрь, 703 нче; 2009 ел, 8 май, 284 нче; 2009 ел, 31 август, 595 нче; 2010 ел, 2 апрель, 227 нче; 2010 ел, 28 июнь, 520 нче; 2011 ел, 22 февраль, 146 нчы; 2012 ел, 23 июнь, 547 нче; 2012 ел, 28 декабрь, 1163 нче; 2014 ел, 8 май, 308 нче; 2015 ел, 9 июль, 502 нче; 2016 ел, 29 декабрь, 1028 нче; 2019 ел, 15 апрель, 295 нче, 2019 ел, 19 ноябрь, 1053 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктта «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы заказчылары өчен үзәкләштереп сатып алына торган товарларның, заказ бирелә торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлегенең 12 пунктындагы өченче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин